КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 27 март г.Казань № б-771

2023 елда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итү һәм Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын үткәрү кысаларында:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына:

2023 елның 29 апрелендә урман фонды территориясендә «Хәтер бакчасы» халыкара акциясен (алга таба – Акция) үткәрүне оештырырга;

тиешле эшләрне башлап җибәргәнгә кадәр хезмәт иминлеге буенча максатчан инструктажны мәҗбүри үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, мәктәпне тәмамлаучылар белән берлектә, Акция үткәрү мөмкинлеген карарга.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына Акциядә катнашырга.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә, Татарстан Республикасының яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре территориясендә Акция оештыруны һәм анда катнашуны тәкъдим итәргә.

5. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Акцияне яктыртуны, шулай ук урманга карата сакчыл мөнәсәбәт турында материаллар бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин